
وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

# Дин вә Мәгыйшәт

№17 (114). 9 декабрь 2011 / 14-мөхәррәм-1433

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Ак юл

▷2-3◁



Россия БМО чыгарган резолюцияне хупламады

▷3◁



Сез нинди оратор?

▷4◁

## ЯҢАЛЫКЛАР

**ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ ИНВАЛИДЛАР УНКӨНЛЕГЕНДӘ КАТНАША**

1 декабрьдә "Тандем" сәүдә һәм күңел ачу комплексында инвалидлар ункөнлеге ачылды. Чара "Апрель" тернәкләндерү үзәге тарафыннан оештырылды. Анда мөмкинлекләре чикләнгән авыру балаларның кул эшләре ярминкәсе узды, аниматорлар чыгыш ясады, балаларга чәй эчертү оештырылды. Чарада ТР мөселманнары Диния нәзарәте хезмәткәрләре, Казандагы Киров һәм Мәскәү районнарының хакимият башлыклары һәм районның социаль яклау вәкилләре катнашты.

**ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮДӘН СОҢ АПАНАЙ МӘЧЕТЕ АЧЫЛДЫ**

2 декабрь көнне Татарстан башкаласында әлегә кадәр сакланган, иң беренче төзелгән мөселман корылмаларының берсе һәм федераль дәрәҗәдәге архитектура һәйкәле булган Апанай мәчетенең ачылу тантанасы булып узды.

Мәчет ачылышында ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов, Казан мэры Илсур Метшин, республикабыз мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз, Чуашстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Әлбир хәзрәт Крганов, РФ Президенты администрациясе вәкиле Илья Баринов, РФ Дәүләт Думасы депутаты Илдар Гыйльметдинов, Апанаевлар нәселенең кардәшләре һ.б. мәртәбәле кунаклар катнашты.

Дин әһелләре дә, җәмәгать эшлеклеләре дә әлеге мәчет ачылышының тарихи әһәмиятен ассызыклап үтте. Республикабыз җитәкчесе мәчеткә Коръән китабы тапшырды. Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз: "Әлеге мәчет ачылу үзенә күрә бер милли-мәдәни кыйбла булып тора. Төзекләндерүгә өлеш керткән иганәчеләргә, республикабыз җитәкчеләренә рәхмәтебезне җиткерәбез. Киләчәктә дә шул рәвешле динебезне бергәләшеп үстерергә, ныгытырга, мөселман кардәшләребез белән бергәләшеп, рухи камиллеккә ирешергә насыйп булсын", - дип билдерде.

**КИЕВТА БЕРЕНЧЕ МӘЧЕТ АЧЫЛДЫ**

2 декабрь көнне Украинаның башкаласы Киев шәһәрендә беренче (һәм әлегә кадәр бердәнбер) мәчет ачылышы тантанасы булды. Әлеге чарада ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең халыкара бүлек җитәкчесе Хәбибулла Нәфисуллин да катнашты. Ул Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз исеменнән Украина мөфтие шәех Әхмәт Тәмимне Европадагы иң зур мәчетләрнең берсе булган "Әр-Рахма" мәчете ачылу белән котлады. **DUMRT.RU**

# Без һәрвакыт сайлау алдында

**Күптән түгел генә Россия Федерациясе Дәүләт Думасына сайлаулар узды. Бу сайлаулар халыкның хөкүмәткә карашының бертөрле булмавын һәм үз киләчәге өчен кайгыртуын күрсәтте. Кешеләрнең яхшы тормышка омтылуы аңлашыла, шуңа да Аллаһы Тәгалә аларга яхшыны-яхшылыкны сайлап алу мөмкинлеген биргән. Билгеле булганча, байлыкка рөхсәт ителгән юллар белән омтылганда гына, мөселманнар өчен игелек була.**

**Коръәни-Кәримдә болай диелгән: "Ий мөэминнәр! Үзара малларыгызны хыянәт, золым юллар белән ашамагыз, мәгәр риза булышканыгыз хәлдә сәүдә белән кәсеп итеп ашагыз. Янә үз-үзегезне яки дин кардәшләрегезне үтермәгез. Дөреслектә, Аллаһ сезнең өчен рәхимле булды". ("Ниса (Хатыннар)" сүрәсе, 29 нчы аять). Бу кешенең иң яхшы нәрсәләрне сайлап алганда гына исәпләнә торган төп билгесе. Ләкин сайларга кирәк булган нәрсәләр турында белем булмаган очракта сайлау кыенлаша. Бу бигрәк тә хәзерге вакытта ачык күренә. Кешеләр үз хокукларын белми, тормышта күп кенә нәрсәләр аларның үз хокукларына бәйле булганлыгын аңламый. Белеме сай кешеләр белән идарә итү җиңел. Шуңа да дөрес сайлау**



**өчен кешегә ГЫЙЛЕМ кирәк. Ә бу инде кешедән тырышлык, максатчанлык, бүтәннәргә һәм үзеңә карата ихтирамлы булуны таләп итә. Чөнки барлык хокуклар да җәмгыять алдындагы бурычлар белән тыгыз бәйләнештә тора. Әгәр дә син, балаңны яхшы, "престиж"лы мәктәптә укытасың килеп, ришвәт бирсәң, андый мөмкинчелеге булмаган башка бала синең аркада ул мәктәптә укый алмаячак. Бу - гаделсезлек һәм башкаларның хокукларын бозу була да инде. Моннан чыгып, үзең өчен яхшы нәрсәне сайлау - башка кешеләр өчен дә яхшылык теләү ул, дип әйтергә була.**

**Мөселман кешесе үзенең төп юлын сайлагандыр инде. Ул ислам динен кабул иткән, әхлаклылык һәм әдәп юлын, Аллаһы Тәгаләнең бу һәм киләчәк тормышта чиксез рәхмәтенә өмет итеп, Аңа илтә торган юлны сайлаган. Бу максатына илтә торган юлда кеше яхшылык яки начарлык, бурыч яки теләк арасында сайлап алу кирәклеге белән очраша. Нәкъ менә шунда ислам дине өйрәткән әхлаклылык кыйммәтләре, ышаныч-теләкләре кулланыла да инде.**

**Илебездә булып үткән сайлауларга килгәндә (кемгә генә тавыш бирсәк тә), сайлаучылар үзләренә хәерле тормыш тели. Бу ният барлык дин кардәшләребезгә, ватандашларыбызга да ирешеп, безне берләштерүче максат булып торса иде.**

**Үзәкләшкән дини оешма – ТР мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

# ТАТАР УНИВЕРСИТЕТЫ

## (Революциягә кадәрге татар мәдрәсәләренең татар филологлары тәрбияләүдәге роле)

***Мәгълүм булганча, 1920 нче еллардан алып XX гасырның утызынчы ел урталарына кадәр әдәбият белеме фәне, татар теле гыйлеме һ.б. гуманитар юнәлешләр нык үсеш ала. Мондый зур үсешкә нинди факторлар сәбәпче булган соң? Әлеге һәм башка сорауларга күптән түгел Казанда узган "Обновленческие движения в исламе" дип исемләнгән халыкара фәнни-гамәли конференциянең татар әдәбияты һәм мәдәнияте мәсьәләләренә багышланган секциясендә КФУдагы Филология һәм сәнгать институты профессоры Эльмира Галиеваның чыгышында җавап табарга мөмкин иде.***

Шушы чорда татар фәнен үстерүгә әдәбият галимнәреннән Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Габдрахман Сәгъди, Җамалетдин Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим, Гомәр Толымбай һ.б.; тел галимнәреннән Гыймадетдин Нугайбәк, Галимҗан Шәрәф, Хуҗа Бәдигый, Гыйбад Алпаров, Вәли Хангильдин, Нигъмәтулла Хәкимов һ.б. зур өлеш керткән. Әлеге галимнәрнең исемнәрен без бик зур хөрмәт белән, олылап телгә алабыз һәм әйтергә кирәк, шул заман хәрәкәтенә, яңа заман фәне, иҗтимагый тормышы хәрәкәтенә алар 1917 елгы революциягә кадәрге татар мәдрәсәләрендә алган белемнәре белән килеп кушылган. Кайберләре хәтта югары уку йортларында да, мәсәлән, Газиз Гобәйдуллинның "Мөхәммәдия" мәдрәсәсеннән соң Казан император университетында, аның тарих-филология факультетында укуын беләбез. Югарыда санап кителгән филолог галимнәребездән Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти һ.б. күренекле затлар "Галия" мәдрәсәсендә укыган. Җамалетдин Вәлиди - Казан губернасы Вятка өязендәге Бубый авылы мәдрәсәсендә белем алган. Газиз Гобәйдуллин, Галимҗан Шәрәф, Хуҗа Бәдигый - Казандагы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен тәмамлаган. Алар мәдрәсәләрдә алган дини һәм дөньяви белемнәрен яңа заман культурасы, яңа заман фән-мәгариф үсеше, аның проблемалары белән үрә алган. Моның өчен булачак галимнәргә мәдрәсәләрдә алган тәрбия һәм белем зур ярдәм иткән.

**Шушы мәдрәсәләрдә алган дини белемнәр планында алар тагын нинди дөньяви фәннәрне үзләштерә алган, аны ничек, ни рәвешле үзләштергәннәр? Яңа заман белеме күренешләрен дини һәм дөньяви белемнәр яссылыгында ничек күргәннәр?..**

Бүгенге көн укучысы өчен әлеге сораулар зур кызыксыну уята торгандыр дип уйлыйбыз. Сезнең игътибарыгызга филология фәннәре докторы Э.Р.Галиеваның чыгышын тәкъдим итәбез.

Эльмира Рәкыйп кызы XX йөздәге 20-30 нчы елларның әдәбият үсешен, татар әдәбияты галимнәренең эшчәнлекләрен өйрәнеп, шул турыда зур хезмәт бастырып чыгарган автор буларак, проблеманың шушы аспектына да игътибар итеп килә икән.

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

*Мирхәт хәзрәт ҖАМАЛИЕВ:*

# "ҮЗЕБЕЗНЕ ТӘРБИЯЛӘРГӘ КИРӘК"

***Апас районы имам-мөхтәсибе Мирхәт хәзрәт Җамалиев "Дин вә мәгыйшәт" газетасына биргән әңгәмәсендә мөхтәсибәт эшчәнлеге белән таныштырды. Ул шулай ук районның дини тормышындагы вәзгыять, андагы проблемалар, хәл ителәсе мәсьәләләр турында да сөйләде.***

- Республикабызның бүтән районнары белән чагыштырганда, Апас районы да мәхәлләләр саны буенча калышмый. Барлыгы 51 мәхәллә бар, мәчетләр дә күп. Шөкер, Аллаһ йортларына ярдәм итүчеләр шактый. Имамсыз торган авылларыбыз юк. Дөрес, дин әһелләренең күбесе өлкән яшьтә. Хәтта сиксән яшьлек имамнарыбыз да бар. Барлык мәхәлләләребезнең ун процентында мәдрәсә тәмамлаган хәзрәтләребез эшли: алар Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге, "Мөхәммәдия" кебек мәдрәсәләрдә белем алган. Аллаһка шөкер, бер генә имамнан да зарлана алмыйм. Һәрберсе хәлдән килгәнчә эшләргә тырыша. Хәзерге вакытта ун имамыбыз Казандагы Коръән курсларында белемнәрен тирәнәйтә. Дин әһелләренең квалификациясен күтәрүгә зур игътибар бирәбез. Узган елларны бу юнәлештә әллә ни эшләп булмаган иде, Иншә Аллаһ, быелдан бу эшне тагын да киңрәк җәелдерергә тырышабыз, - дип башлады үз сүзен Мирхәт хәзрәт. - Мәчетләребезгә килгәндә, аларның барысы да диярлек газлаштырып бетерелгән. Илле бер мәчетнең кырыгы бүгенге көндә газ яга. Якын арада барлык мәчетләрдә дә газ булачак. Коммуналь түләүләрне вакытында түләп барабыз. Бу яктан әллә ни проблема юк. Тик бу түләүләрне түләү буенча кайвакыт кыенлыклар килеп чыга, Аллаһның рәхмәте белән анысын да чишәргә тырышабыз.

*(Ахыры 2 нче биттә.)*



## Энҗе САБИРОВА:

# "Яулык – эшкә кергәндә киртә түгел!"

Күптән түгел генә "Алтын урта"ның кызлар клубында Энҗе Сабирова белән очрашу үтте. Энҗе - "Моё любимое" ательесының хуҗасы. Мөселман кызларына ул кием сайлау, яулык белән күлмәкне килештерү, кием тектерү, төсләр сайлау һәм үз бизнесыңны башлау буенча мастер-класс үткәрде, ягъни киңәшләрен бирде.

**ALTINURTA.RU**
**Ләйсән** Фәтхетдинова **фотосы**


# АК ЮЛ

***"Бала чакта без малайлар белән җыелышып мәчеткә йөри идек. Ишек бусагасына утырып олылар артыннан намаз укып дога кылабыз. Онытылып сөйләшеп китсәк, мәчетнең мөтәвәллие безне кисәтә, чыгарып җибәрәм, дип тә әйтеп куйгалый. Ул вакытта Казаков исемендәге мәчет хәзерге Татарстан - Акком асты һәм Гражданнар (Тегәрҗеб) урамнары арасында калкулыкта тора иде.***

Рамазан айларында мәчет алдында кәләвә сату була иде. Олылар өләшкән вак акчаларны җыеп, кәләвә алып ашыйбыз, бигрәк тәмлесе - "талкыш" дип аталганы хәтердә калган. Бәйрәм көннәрендә мәчеттән чыккан халык урам буйлап "Аллаһу әкбәр" дип тәкбир әйтеп бара иде. Ул урыннарда хәзер истәлекле йортлар калмаган, күп катлы йортлар салынган", - дип сүзен башлады, үзенең балачагын искә алып, сугыш һәм хезмәт ветераны, рәссам Мансур Зыятдин улы Рәхимов.

Казандагы Иске Татар бистәсендә дөньяга килеп, үткән заман рухын бүгенге көнгә җиткерүче олпат рәссамнәребезнең берсе Мансур Рәхимов тарихыбыздагы бик күп мөхтәрәм зыялыларыбызның портретларын иҗат итеп, алар яшәгән, аралашкан мохитне якты, җылы төсләр белән бүгенге укучыга җиткергән. Халкыбызның ике бөек шәхесе, мәгърифәтче, акыл иясе - Ш.Мәрҗани һәм К.Насыйриның портретлары - Мансур Рәхимов иҗатының кульминацион ноктасын тәшкил итә.

Халкыбызны нинди генә авыр заманнарда да иман ныклыгы саклап калган. Мансур Зыятдин улы моны яхшы аңлап, күңеле белән тоеп эш итә. Аерым портретларга штрихлар тудыруда гына түгел, татарның бөек улларына багышланган рәсемнәрдә дә диннең әһәмиятле урын алып торуын күрергә мөмкин. М.Җәлил һәм А.Алиш сурәтләнгән "Җәза алдыннан" картинасы... Җәлилнең куллары Коръәнгә үрелгән, аның каршысында – имам. Иман ныклыгы һәм ныклы ихтыяр көче белән дошманга каршы тору бөек җиңүгә алып килгән дә инде.



Икенче бер рәсемдә К.Насыйри үзенең авылдашлары арасында: арткы планда сурәтләнгән мәчет манарасыннан ай балкый, бөек мәгърифәтчене каршы алырга имамнар да, кәләпүшле, түбәтәйле авыл агайлары да чыккан... Ягъни татарларда элек-электән мәгърифәт һәм дин кулга-кул тотынышып, милләтне үстерүгә хезмәт иткәннәр.

"Мотыйгия" мәдрәсәсе бинасы, Иске Таш мәчет, Апанаевлар йорты... Тукайның җеназасын укыган Зариф хәзрәт Әмирханов, Апанай мәчете имам-хатыйбы Мөхәммәдкасыйм хәзрәт Салихов, дин әһеле, мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәси... Динебезне үстерүгә үзләреннән олуг өлеш керткән шәхесләребез, күпме истәлекләрне үзләренә сыйдырган тарихи биналар, мәчетләрне Казан шәһәренең Ш.Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясендә оештырылган Мансур Рәхимовның шәхси музеенда очратырга мөмкин...

М.Рәхимов әлеге дин әһелләре белән шәхсән таныш булмаса да, шул мохиттә тәрбияләнгән, алар турындагы истәлекләр белән таны-

**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

## Мирхәт хәзрәт ҖАМАЛИЕВ:

# "ҮЗЕБЕЗНЕ ТӘРБИЯЛӘРГӘ КИРӘК"

**- Уку-укыту эшләре җайга салындымы? Бу юнәлештә нинди кыенлыклар бар?**

- Бездә укыту эшләре дә бер җайга салынып бара. Апас Җәмигъ мәчете эшли башлаганнан бирле, бу эш тагын да җиңеләя төште. Хәзерге вакытта моңа мөхтәсибәттә уку-укыту бүлеге җитәкчесе Шаһит хәзрәт җавап бирә. Ул бик тә булдыклы, әдәпле кеше. (Хәзрәт үзе Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсәдә укыган.) Ел саен бездә җитмешләп кеше белем ала, аларның күбесе хатын-кызлар. Узган елны егерме бишләп ир бала укып чыкты. Быел әлегә 10-12 генә бала йөри. Иншә Аллаһ, аларның саны артыр, дип уйлыйбыз. Барлык укытучыларыбыз да югары белемле. Авыл җирлекләрендә дә уку-укыту җайга салынган. Күбесендә - Чирмешән, Багыш, Йомралы, Каратун, Кече Күккүз, Морзалар кебек мәхәлләләрдә уку-укыту эшләре әйбәт кенә бара. Саннарга килгәндә, укучылар төрлесендә төрле: икедән алып ун-унбишкә кадәр шәкерте булган мәчетләр бар. Уку-укыту эше мөфтияттән бирелгән программа нигезендә алып барыла. Бары тик тәкъдим ителгән китапларны гына файдаланабыз. Хәнәфи мәзһәбенә нигезләнеп эшлибез, читкә тайпылганыбыз юк. Китаплар да, уку-укыту әсбаплары да шуның буенча көйләнгән, Аллаһка шөкер. Мөгаллимнәрне көнлек, айлык, перспектив планнар төзергә өйрәтәбез. Мәктәпләрдәге тәртипне үзебезгә дә кертергә тырышабыз. Бу эш инде бездә ике-өч елдан артык бара. Кыенлыклар булса да, тырышабыз.

**- Халык белән ни рәвешле эшлисез? Имамнар арасында аңлашылмаучанлыклар килеп чыкканы юкмы?**

- Халык белән эшләүгә килгәндә, аеруча зур активлыкны дини бәйрәмнәрдә күрсәтергә тырышабыз. Апас муниципаль районы хакимияте дә бу мәсьәләләр буенча зур ярдәм күрсәтә. Ифтар табыннары, корбан ашлары администрация тарафыннан катгый рәвештә әмер итеп куела. Ул һәрбер оешма-хуҗалыкта да үткәрелә. Мәчетләребез дә бу юнәлештә зур эш алып бара. Гает көннәрендә кеше күп җыела, бернинди дә ыгы-зыгы булганы юк. Халык хөтбә-вәгазьләрне тыныч, әдәпле генә тыңлап утыра. Сораулар да темасына карата гына бирелә. Аллаһка шөкер, без шундый тәртип булдыра алуга ирештек. Чөнки алдагы елларда бездә фетнәләр дә чыгып алган иде.

Авылларга да йөрергә тырышабыз, елына бөтенесен дә әйләнеп чыгабыз. Мөхтәсиб буларак, мин үзем генә түгел, ярдәмчеләрем дә чыккалый, әйтик, Җәмигъ мәчеттән Рәшит хәзрәт тә йөри. (Ул шулай ук атна саен Йомралы авылында дәресләр дә бирә.) Шаһит хәзрәт һәм башка югары белемле имамнарыбыз да авылларга йөри. Дингә ихластан бирелгән Гамиров Азат абый бар, ул авылларга барып намаз, җомга укыту тәртипләрен өйрәтеп йөрде. Җәй көннәрендә ул туган авылына барып имам да булып тора. Апасның үзендә дә берберсенә ярдәмләшеп эшли торган хәзрәтләребез шактый. Коръән укыту, мәет күмү йолаларын башкарганда да берберебезгә булышабыз.

**- Мөхтәсибәттә тагын нинди оештыру эшләре алып барасыз?**

- Мөхтәсибәтебездә быелдан яшьләр белән эшләү бүлеге дә булдырдык. Һәрбер мәхәлләдә ревизия комиссиясе бар. Аларның әгъзалары утырыш беркетмәсе белән беркетелгән. Район халкы белән аңлашып эшлибез. Зур фетнәләр чыкканы юк. Булган проблемаларны вакытында чишәргә тырышабыз. Яшьләр килгәч, олы имамнардан үз урыннарын бушатуларын сорыйбыз. Кайбер имамнар бик китәргә ашыкмый. Без аларны белем дәрәҗәсенә карап түгел, саулык-сәламәтлекләренә карап азат итәбез. Аннан соң, мәзһәбебезгә каршы булган дин әһелләрен тәрбияләргә тырышабыз. Хәзер халык грамоталы. Радио-телевидение, массакүләм мәгълүмат чараларыннан информация ала. Ул диндәге вәзгыятьне аз гына булса да чамалый. Һәм имамның авызыннан чыккан сүзне ул башкасы белән чагыштырып карый. Шуннан соң үз фикерен әйтә. Шуңа күрә динне төптән, аны фәнни нигезләп аңлатып бирә алырлык хәзрәтләр кирәк безгә. Мәдрәсә, институт бетергән имамнар кирәк. Белемле имамнар килгәч, аларны өлкән хәзрәтләребез урынына билгелибез. Ләкин куып чыгармыйбыз, алар шунда кала, ярдәмче булалар. Аксакаллар шурасы оештырып, шуларга әгъза итеп куябыз.

**- Яшьләр белән эш ничек бара?**

- Яшьләр белән эшләүгә килгәндә, бу юнәлештә проблемалар бар әле. Ачыктан-ачык әйтергә кирәк, яшьләр белән эшләп бетермибез. Яшьләребез килә, алар белән эшләргә тырышабыз. Җәмигъ мәчеттә узучы җомга намазына баштагы чорда ун-унике генә кеше килгән булса, хәзер илледән артык кеше җыела. Дөресен әйтергә кирәк: анда яшьләр күбрәк. Район үзәгендә ике мәчет бар. Иске мәчеттә дә яшьләр күренә башлады. Аларга өндәү җитми. Киләчәктә яхшылап яшьләр белән бергә эшлисе иде. Хәзер яңа технологияләр, интернет заманасы. Сайтларга мәкаләләр, тәрҗемәләр биреп барасы, блоклар ачасы иде. Шул юнәлештә эш алып барырга ниятлибез, яшьләр кирәк. Олы яшьтәгеләр компьютер белән барысын да эшләп бетерә алмый. Яшьләрне шуңа тартабыз. Өстәвенә, соңгы вакытта мәктәпләр белән эшләүгә тагын да зур ихтыяҗ туды. Терророчылык, экстремизмга каршы профилактика эшен киң җәелдерәбез. Кайберәүләр интернетта булган кирәксез сайтларга кереп, ваһһабчылык рухындагы темаларны күреп, шуның белән адашып китә. Бездә дә булды шуның ишеләр. Алар белән без сөйләшеп, көрәшеп карадык та, Аллаһның рәхмәте белән алар китәргә мәҗбүр булды. Чөнки алар халык арасында шундый фикерне тарату гына түгел, бирeдәге "урын" өчен дәгъват кыла башладылар. Без аларның фикерләрен тыңлап, әлегә алар белән эшләү ярамас, дип торабыз. Андыйларга: "Бар, монда йөрмәгез", - дип әйтмибез, чөнки алар да мөселманнар. Фикерләрен тыңлап, дөрес юлга бастырырга тырышабыз. Иншә Аллаһ, киләчәктә үзләре дә аңлап килерләр. Чөнки басым көчле. Ул юнәлешләр бездә генә түгел, республикабызның башка районнарында да бар. Илендә дә бетмәгән әле ул. Әлеге яшьләр, бәлки, динебезне фундаменталь тотарга тырышалардыр, әмма безгә үзебезне тәрбияләргә кирәк. Авыл-районнарыбызда һәр кешегә якын килеп эшләргә кирәк. Чит җиргә чыгып китеп, анда дәгъват кылып йөрү - минемчә, ул әлегә артык нәрсә. Безнең үзебездә дә кешеләр җитәрлек. Гыйлеме бар икән, имам-мөхтәсиб белән сөйләшеп, уртак тел табып, халык арасына барып, тематиканы үзебезнең мәзһәбкә көйләп эшләсен. Җиһадка, кораллы көрәшкә чакырырга кирәкми. Халыкның болай да башы каткан, аны хәлифәт төзергә чакырасы юк. Гади генә хикмәт кирәк. Шул рәвешле дәгъват кылсалар, без каршы түгел.

**- Сездәге ул кешеләр "ваһһабчылык" дигәнне аңлап эш итәме? Дәүләт структуралары, мөфтият бу хакта хәбәрдармы, ярдәм итәләрме?**

- Дөньяда "ваһһабчылык" дигән сүз барлыкка килде. Радикаль агымнарга бирешүчеләрне моның белән чагыштыру дөрестерме-юктырмы, хәзер анысын тикшереп тормыйм. Ләкин боларга каршы без катгый рәвештә эш алып барабыз. Полиция, участковыйлар һәрчак безнең янәшәдә. Мәчетләргә килеп, нindидер дәгъват белән йөрүчеләрне Авыл Советлары да күзәтә. Без мондыйларны тыябыз. Алар иң беренче чиратта мөхтәсибәткә килергә тиеш. Фикерен аңлатып, путёвкасын алып, имамнарга график буенча җибәреп, шул рәвешле чыгып йөрсәләр генә рөхсәт бар. Легаль булмаган юлларны сайлап эшләп йөрүчеләрне - тагын бер кабатлап әйтәм - тыябыз. Безнең хакимият башлыгы да ул тискәре нәрсәләргә каршы. Хакимият башлыгы: "Хәзрәт, сез ул мәсьәләдә бик тә уяу булыгыз, ярдәм итәрбез", - дип тора. Без тынычлык яклы. Экстремизм буенча районда җыеннар үткәрдек. Шундый ук җыеннар безнең мәктәпләрдә дә узды. Аннан соң безнең районның башкарма комитетында Антитеррор дигән комиссия бар, мин үзем шунда әгъза булып торам. Киңәшеп, аралашып, фикерләшеп торабыз. Нәтиҗәле эшлибез. Эчке эшләр бүлеге белән дә элемтәдә торабыз. Мондый күренешләрне күзәтеп торырга тырышабыз. Әмма, барыбер булгалый. Каян да булса килеп чыккалыйлар. Алар күпсанлы түгел, вакытында туктата алабыз. Мөфтияттә дә безне якын кабул итәләр, читкә тибәрмиләр. Ләкин мактанырга иртәрәк әле, эшлисе эшләребез бик күп. Шуларны эшләргә Аллаһы Тәгалә насыйп әйләсә иде. Мөфти Илдус хәзрәт Фәиз безгә һәрдаим ярдәм итеп тора, мөрәҗәгатьләребезне кире какмый.

**- Киләчәктә кайсы юнәлешләр буенча ныклап эш алып барырга ниятлисез?**

- Киләчәктә Апас районындагы барлык яшьләрнең - 35-40 яшькә кадәр булган бөтен кешенең исемлеген алып, зур чара (форум, конференция, мәҗлес) үткәрмәкче булабыз. "Дин вә мәгыйшәт" газетасының 23 сентябрь санында (№ 6) Җәлил хәзрәт Фазлыевның балалар бакчалары, мәктәпләр белән эшләү турында мәкаләсе басылган иде, без аны бик зур нәсихәт буларак кабул иттек. Шул мәсьәлә буенча сөйләшүләр алып барып, программалар төзеп эшләргә ниятлибез. Безнең Апас мөхтәсибәтендә Мөслимәләр берлеге эшләп килә, аңа Самалианова Дания ханым җитәкчелек итә. Аның ярдәме белән район газетасы аша ай саен бездә "Ислам нуры" газетасы чыгып килә һәм югарыда санап кителгән мәсьәләләрне хәл итүдә аның да ярдәме зур булыр, дип уйлыйм.

***Әңгәмәдәш - Нияз САБИРҖАНОВ***



шып, олуг шәхесләребезнең дуслары, туганнары, фикердәшләре белән аралашып, халыкка аларны "кайтарырга" ашыккан.

Рәссам архивындагы татар тормышына багышланган кайсы гына рәсемне алсак та, йортның түрендә шәмаил булыр, татар агайлары башында - түбәтәй, өстәлләрендә - Коръән һәм иң сокландырганы - геройларының күзләрендә иман нуры, милләт алдында олы җаваплылык хисе...

Гасырлардан гасырга рәссамнар гына түгел, иҗат иткән рәсемнәр дә үзгәрә бара, замана төсмерен ала. Шулай да әхлакый кыйммәтләр үзгәрми икән. Әлеге нечкәлекләрнең асылын тоемлаган каләм әһелләре, үзләренең иманнарына тугры калып, рухи кыйммәткә ия булган рәсемнәр иҗат итә. Мансур абый Рәхимовның рәсемнәре - моның ачык мисалы. Мәдәни, тарихи һәм дини кыйммәткә ия булган рәсемнәр, тарих тузаннарына күмелеп, буыннар арасында югалмый... Алар күңелнең түренә уелып, һәрдаим алгарышка әйдәп тора.

Унынчы дистәсен ваклаучы рәссам бүгенге көндә дә актив эшли: иманы нык, күңеле саф булган халәттә иҗаттан аерылу мөмкин түгел шул. Җәмгыятьтәге һәрбер үсеш-үзгәреш, тарих-заманага аның үз карашы. 2011 елның җәендә ясалган "Ак юл" рәсеменә генә күз салыйк: куллары догага күтәрелгән түбәтәйле татар егетенең йөзендә уйлану, борчылу сизелә... Рәсемнең алгы планыннан күтәрелгән Ак юл китапка барып тоташа. Автор шул рәвешле яшь буынны мәгърифәткә чакырадыр сыман. Борынгыдан килгән - китапка карата булган олылау, зурлау, хөрмәтне бүгенге көндә күпләр онытып бара. Мансур абый үзе: "Урамга чыгып йөрмәсәм дә, бүгенге вәзгыять белән танышып барам. Милләтебезнең, татар халкының киләчәге уйландыра, яшьләрнең китапка битараф булулары, интернетта гына утырулары борчый, күңелгә шом сала. Әлеге "Ак юл" рәсеме дә китапка мәдхия буларак иҗат ителгән иде", - ди.

Ак юллар кая гына илтми... Мансур абыйлар буыны салган Ак юллар илебезгә Бөек җиңү бүләк итте, иман ныклыгы тапшырды, рухи сафлык иңдерде... Буыннардан өзелмичә килгән Ак юлларны аклыйсы бар иде...

***Алинә БИКМУЛЛИНА***

# Россия Сүриягә карата БМОдагы кеше хокуклары буенча шура чыгарган резолюцияне хупламады

***2 декабрь кичендә Берләшкән милләтләр оешмасындагы (БМО) кеше хокуклары буенча шура, "даими рәвештә һәм җитди булган кеше хокукларын бозу"да гаепләп, Сүриягә карата резолюция чыгарды. Сүз җәзалап үтерүләр, суд карарыннан башка кешеләрне кулга алулар, җәберләүләр, көчләүләр турында бара. Бу хакта "Эхо Москвы" хәбәр итә.***

Шул ук вакытта дүрт ил - Россия, Кытай, Куба һәм Эквадор резолюцияне хупламады. Россия дипломаты биргән аңлатмаларга караганда, документ "бер яклы гына килеп чыккан һәм ул сәясиләштерелгән". Моннан тыш, Мәскәүдә исә резолюция Сүриянең эчке эшләренә тыгылуга һәм аның хәзерге хакимиятен бәреп төшерүгә китерер дип шикләнәләр.

БМОдагы Сүрия вәкиле Файсаль Хаббаз Хамуи резолюцияне сәясиләштерелгән һәм ул Сүрия белән мөнәсәбәтләрне туктатуга китерә торган дип атады. Дипломат БМОга кергән илләрне резолюциягә каршы чыгырга чакырды.

Аңа хәтле Сүрия властенә карата тыюлар Гарәп илләре лигасы, АКШ, Европа берлеге (Евросоюз) һәм күрше Төркия тарафыннан кертелгән иде.

Исегезгә төшерәбез: Сүриядәге киеренкелек моннан сигез ай элек, гарәп илләрендәге вакыйгалар ныклап куера башлагач, җитди төс алган иде. Коралланган һәм читтән идарә ителүче оппозиция, Президент Башар Асадның отставкага китүен һәм илдә реформалар үткәрүне таләп итеп, урамнарга чыкты. Хөкүмәт исә аны хәрби көч ярдәмендә бастыра башлады. Нәтиҗәдә, бу ике яктан да зур югалтуларга китерде.



***БМОдагы кеше хокуклары буенча шура Сүриягә карата резолюция чыгарды.***

# ТАТАР УНИВЕРСИТЕТЫ




**(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)**

Тикшереләчәк фәнни мәсьәләләр галимәнең "Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе" дип аталган монографиянең (Казан: Фән, 2002) дәвамы булыр, дип көтелә. Конференциядә Э.Р.Галиева санап чыккан филолог галимнәрнең биографияләре, эшчәнлекләре, мәгълүм булган мәдрәсәләр материаллары үрнәгендә аларның ни рәвешле галим булып формалашулары һәм шул мәдрәсәләрнең роле ничек булганлыгы турында күзәтү бирде.

- Тик, кызганыч, менә шушы мәдрәсәләрдә бирелгән дини һәм дөньяви белемнәрнең симбиозы мәсьәләсе әле татар фәнендә өйрәнелмәгән, хезмәтләр язылмаган. Мәсьәлә җентекле өйрәнүне таләп итә, - дип башлады үз сүзен профессор Э.Галиева. - Шунысын да әйтеп үтәргә кирәк: дини һәм дөньяви белемнәр симбиоз факторы ул чордагы татар мәдәнияте өчен генә түгел, ул, гомумән, башка халыклар культурасы өчен дә типик күренеш булган. Әйтик, русларда семинарияләрдән университетларга килгәннәр.

Татар мәдрәсәләре XIX гасыр ахырлары - XX гасыр башларыннан алып 1917 елгы инкыйлабка кадәр яшәп, эшләп килгән. Равил Әмирханов хезмәтләрендә әйтелгәнчә, "Галия", "Мөхәммәдия", Иж-Бубый мәдрәсәләрендә бик төпле дини белем бирелү белән бәррәттән, гимназия курсына караган дөньяви предметларны укытуны да күздә тоткан, яңа типтагы, җәдиди юнәлештәге уку йортлары булган. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсе турында Равил Әмирханов: "Чын мәгънәсендә, Октябрьгә кадәрге "татар университеты" дип атарга мөмкин", - ди. Ә менә Иж-Бубый мәдрәсәсе турында ул чорда ук рус интеллегенциясе, татар зыялылары арасында "мөселманнар академиясе" дип йөртелү турында язалар. Үз вакытында Галимҗан Ибраһимов иҗатын өйрәнгән академик Мансур Хәсәнов әдип белем алган "Галия" мәдрәсәсен "милли институт дәрәҗәсендәге мәшһүр уку йортларының берсе" дип атаган иде. Халык арасында шушы "Галия" мәдрәсәсе турында "халык университеты тибындагы уку йорты" дигән исем дә йөри. Нәрсә генә дисәк тә, без санап узган мәдрәсәләр үз вакыты өчен шактый төпле белем биргән, системалы, күпкырлы шәхес тәрбияли торган уку йортлары булган. Аларның уку-укыту программалары шушы мәдрәсәләрнең яшәве, эшләве дәвамында камилләшә барган. Тагын шундый фикер бар: иң алдынгы мәдрәсәләрнең, әйтик, шул ук "Галия", "Мөхәммәдия", Иж-Бубый мәдрәсәләрендәге уку программалары шул чор Россиядәге гимназияләр, реаль училищелар һәм Казан татар укытучылар мәктәбе программаларына бик якын торган, шундагы предметларның спектры белән бик якын булган. Шуңа күрә Иж-Бубый мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, Җамалетдин Вәлидигә туганы Садри Җәләл белән Казан татар укытучылар мәктәбенә кереп уку кыенлыклар тудырмаган. Татар мәдрәсәләрендә дини белем бирүнең мәгърифәтчел принциплары хакында да ассызыклап үтәсем килә. Революциягә кадәрге татар мәдрәсәләренең төп максаты - ислам дине юнәлешендәге белем бирү, әдәпле, грамоталы шәхесләр әзерләү булган. Төп белем һәм культура чыганагы ислам динендә булган. Татар мәдрәсәләрендә дини белем бирүне мәгърифәтлелек, гуманлылык планында карау кирәктер. Дини предметлар рухи, гуманистик башлангыч биргән. Утыз Имәни: "Мәгърифәтле, гыйлемле булу - Коръәнне белү ул", - дигән. Белем алуны татар зыялылары ике аспектта: туры мәгънәсендә мәгариф (образование) һәм рухилыкны тәрбияләү (воспитание духовности) яссылыгында кабул иткән. XX йөзнең егерменче еллар әдәби хәрәкәтендә актив катнашкан күренекле тәнкыйтьчеләр - Галимҗан Нигъмәти һәм Җамалетдин Вәлиди турында сүз алып барганда, без аларны әхлакый йөзләрен җуймаган галим-әдәбиятчылар буларак карый алабыз. Бүгенге көндә дә аларның әдәпле шәхес булулары турында язалар. Бу, барыннан да бигрәк, мәдрәсәләрдән килгән тәрбия нәтиҗәсе булгандыр инде. Әлеге тәнкыйтьчеләр үзләренең каләмдәшләрен нахакка кыйнамаган, әдәби судларда катнашып намусларын сатмаган. Боларның һәммәсе дә мәдрәсә тәрбиясенә барып тоташа, алар дини әхлак нигезләрен гомерлек маяк итеп алган. Алай гына да түгел, татар мәдрәсәләрендә дини предметлар белән дөньяви фәннәрнең киң спектрлы укытылуы шәкертләрдә актив фикерләү сәләтен үстергән, өйрәнелә торган предметларга карата иҗади мөнәсәбәт тәрбияләгән. Менә бу соңрак галим булып китәчәк шәкертләргә, татар галимнәре формалашуга җитди этәргеч ясаган. Мәдрәсәләрдә бик әзерлекле укытучылар укыткан. "Галия", "Мөхәммәдия" мәдрәсәләрендә Мисыр, Сүрия, Төркия, Россия, Көнбатыш Европа уку йортларында белем эстәгән укытучы кадрлар эшләгән. Әйтик, Иж-Бубый мәдрәсәсенә нигез салган Бубыйларның берсе - Нигъмәтулла Бубый Мисырның Каһирә шәһәрендәге "әл-Әзһар" университетында, икенчесе - Габдулла Бубый Төркиядә укыган. "Галия"не җитәкләгән Зыя Камали, "Мөхәммәдия"гә нигез салган Галимҗан Баруди шулай ук үз вакыты өчен гаять зур гыйлем иясе булган. Алар үз укучыларында фикерләү сәләте булдыруга, аны үстерүгә аеруча зур игътибар биргән. Мәдрәсәләрдә шәкертләрнең фикер үсешенә зур этәргеч биргән мантыйк (логика) предметы укытылу зур игътибарга лаек. Шунысы үзенчәлекле: бу фән "Галия"дә, "Мөхәммәдия"дә һәм шулай ук "Бубый"да "моназарә" (искусство дискутирования) дигән махсус фән буларак та укытылган. Шәкертләрне полемика логикасына һәм аны алып бару логикасына өйрәткәннәр. Ә бу исә булачак әдәбиятчыларга хас сыйфатларны тәрбияләү өчен хезмәт иткән. Галимҗан Ибраһимов, Галимҗан Нигъмәти, Җамалетдин Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим һ.б. галимнәр узган гасырның 20-30 нчы елларында татар әдәбияты, татар теле, татар тарихы фәннәренең формалашуында һәм үсешендә мөһим роль уйнаган. Аларда фәнни фикер активлыгы өстенлек иткән. Бубый мәдрәсәсендә алган белемнәре Җамалетдин Вәлидигә "Вакыт" газетасында, "Шура", "Аң" журналларында эшчәнлек алып барырга зур мөмкинлек биргән һәм ул иҗтимагый һәм эстетик фикер үсешендә дә актив катнашкан. Заманында күренекле уку йортларыннан саналган "Хөсәения" мәдрәсәсендә татар теле һәм әдәбияты буенча мөгаллимлек итү өчен дә аның Иж-Бубыйда алган белемнәре нигез булып торган. "Галия" мәдрәсәсендә алган белемнәре белән Галимҗан Нигъмәти укуын XX йөзнең егерменче елларында Мәскәү дәүләт журналистика институтында, аннан шул ук Россия башкаласында КУТВта (Коммунистический университет трудящихся Востока) дәвам иттерә. Аның алган белемнәре яңа заман Россия уку йорты югарылыгына күтәрелерлек җирлек бирә алган. Һәм аның "Галия"дә үзләштерелгән предметлары - рус теле һәм әдәбияты, Россия тарихы, гомуми тарих, география, фәлсәфә, хокук, мантыйк (логика) һ.б. буенча алган белем әзерлеге югары уку йорты программаларындагы рус теле һәм әдәбияты, Көнбатыш әдәбиятлары тарихы, Россия тарихы, Көнбатыш тарихы (история Запада), сәяси-икътисади география, физик география, тарихи материализм, хокук, логика һ.б. предметларны өйрәнүгә зур этәргеч бирә. (Бу фәннәр XX гасырның егерменче елларына караган укыту программалары материалларыннан алынды.) Революциягә кадәрге алдынгы мәдрәсәләрдәге уку-укыту программаларына кергән Коръән нигезләре, Көнчыгыш фәлсәфәсе, тарих предметларын төптән, нигезле үзләштерү Газиз Гобәйдуллин, Гомәр Толымбай, Галимҗан Нигъмәтиләр өчен соңыннан Мәскәүдәге Кызыл профессура институтында укыганда шулай ук ярдәм иткән. Әле санап үтелгән галимнәр XX йөзнең егерменче еллары башларында Казанда Көнчыгыш педагогия институты оештырылгач, татар әдәбияты, татар теле, татар тарихы, шәрык әдәбияты һ.б. предметларны укытуга алыналар.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: әүвәл мәдрәсәләрдә укып, аннан югары уку йортларында белем алу безнең галимнәребезгә дини һәм дөньяви белемнәрне синтезлау мөмкинлеге бирә. Мәдрәсәләрдә һәм Россия, совет чоры югары уку йортлары программаларында охшаш моментлар булуы (изоморфизм) ачыклана. Шушы дини һәм дөньяви фәннәр симбиозы татар галимнәренең эшчәнлекләрендә дә, гыйльми хезмәтләрендә дә чагылыш таба.

Әлеге һәм башка мәсьәләләрне татар фәнендә тагын да ныклап өйрәнү таләп ителә.

***Нияз САБИРҖАНОВ***

ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ

# Сез нинди оратор?

***Аудитория каршында чыгыш ясаучыларның (лектор-укытучы, вәгазь сөйләүче, доклад укучы, киңәш бирүче) тыңлаучылары белән аралашуының үз стиле була, әмма аларны да ике зур төркемгә бүләргә мөмкин.***

Беренче төркем вәкилләре аудиторияне үзләренә буйсындыра. Алар аудиториянең чыгышка булган бәһасен исәпкә ала, әмма "дилбегә"не үз кулларында тотуны кулайрак күрә. Үз-үзен тотышында һәм сөйләмендә тыйнаксызлык күрсәтми. Мондый стильне "авторитар" дип атыйк. Икенче төркемгә караучылар, мәгълүм бер дәрәҗәдә, үзе үк аудиториягә буйсынган. Аның трибунадан аралашуында, сөйләме һәм үзен тотышында күпләгән ысуллары була. Ул аудиториянең турыдан-туры бәясенә өметләнә, аралашуның сизгер, зирәк, "шәхси" гадәтләренә ия була. Мондый аралашучыны "демократик" рухта аралашучы дип атыйк.

Тегесенең дә, монысының да үз өстенлекләре һәм кимчелекләре бар. Шул рәвешчә, чыгыш ясаучының кирәгеннән артык мөстәкыйльлеге аны тыңлаучыларының теләк-омтылышларына битараф калдырырга мөмкин. Ә аудиториядәге барлык кешеләрнең дә мәнфәгатен канәгатьләндерергә тырышу абруй югалуга, чыгышның нәтиҗәлелеге кимүгә китерә.

Аудитория белән аралашуның кайсы тибы кулайрак соң? Аны үзеңнең холык-фигылең һәм башка шәхси сыйфатларың нигезендә сайларга кирәк. Сез үзегезнең кайсы типка каравыгызны түбәндә китерелгән гап-гади тест ярдәмендә ачыклый аласыз.

**Сорауларга "әйе" яки "юк" дип җавап бирегез.**

1. Сезгә һәрбер чыгышка җентекләп әзерләнергә кирәкме, сез аудиториянең үз-үзен тотышына, яшь, җенси һ.б. аерымлыкларына игътибар итәсезме?
2. Сез үзегезнең чыгышыгыздан соң хәлсезлек (авыр бушану) сизәсезме? Шул көнне бүтән чыгыш ясый алмаслык хәлгә килгәнегез, эшкә сәләтегез кисәк кенә түбәнәйгәне юкмы?
3. Трибунага (мөнбәргә) чыгар алдыннан була торган дулкынлануны җиңеп, чыгыш ясаганыгыз (вәгазь сөйләгәнегез) булдымы?
4. Чыгышыгызны (вәгазегезне) һәрвакытта да бертөрле башлыйсызмы?
5. Чыгышка (вәгазьгә) алдарак киләсезме?
6. Аудитория белән беренчел танышу һәм үзегезне тыңлауларына ирешү өчен сезгә шактый зур вакыт (3-5 минут) таләп ителәме? Сез моңа мохтаҗмы?
7. Катгый билгеләнгән тәртип буенча сөйләргә омтыласызмы?
8. Чыгыш (вәгазь) вакытында хәрәкәтләнәсезме?
9. Чыгыш ясаганда (вәгазь сөйләгәндә) сезгә бирелгән сорауларга төркемләмичә генә җавап бирәсезме?
10. Сез чыгыш дәвамында шаярта аласызмы?

## ТЕСТКА "АЧКЫЧ"

*__1, 4, 5, 6, 7, 9__ нчы сорауларга уңай һәм __2, 3, 8, 10__ нчы сорауларга тискәре җавап бирүегез сезнең беренче төркем аралашучы булуыгыз хакында сөйли. Әгәр дә сез __2, 3, 5__ нче сорауларга "юк" дип җавап биргәнсез икән, нерв системагызның көчле типка керүе турында әйтергә мөмкин. __1, 4, 6, 10__ нчы сорауларга тискәре җавап бирүегез хис-тойгы халәтенең хәрәкәтчән (көчемле) булуы турында сөйли.*

*Беренче һәм икенче төр аралашучыларга эчтәлекләрен камилләштерү өчен нәрсә тәкъдим итәргә мөмкин соң? Беренче төркемгә караучыларга - чыгышның тел чараларына һәм эчтәлегенә, композициясенә кагылышлы бар нәрсәне алдан күздән кичерергә һәм кабатлап чыгарга, тулы конспект (хәтта сез кәгазьдән укырга теләмәсәгез дә) төзергә кирәк; икенче төркемгә исә чыгыш ясаганда рухи һәм физик хәзерлекле булырга, йөз-кул хәрәкәтләре белән сөйләмнең юлара мәгънәсе тәңгәл килүенә игътибар итәргә кирәк. Аудитория белән аралашуның үзегезгә генә хас булган гадәт уйлап табарга тырышыгыз.*

**Төзеде: филология фәннәре докторы, КФУ профессоры Гаптрәүф НУРИЕВ**

ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ ТЕСТ

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 10.12.2011 | 7:31 | 09:01 | 13:02 | 15:08 | 16:10 | 17:40 |
| Якшәмбе | 11.12.2011 | 7:32 | 09:02 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Дүшәмбе | 12.12.2011 | 7:33 | 09:03 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Сишәмбе | 13.12.2011 | 7:34 | 09:04 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Чәршәмбе | 14.12.2011 | 7:35 | 09:05 | 13:02 | 15:07 | 16:09 | 17:39 |
| Пәнҗешәмбе | 15.12.2011 | 7:36 | 09:06 | 13:02 | 15:07 | 16:09 | 17:39 |
| Җомга | 16.12.2011 | 7:37 | 09:07 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Шимбә | 17.12.2011 | 7:38 | 09:08 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |

# Татар җәмәгатьчелеге зур югалту кичерде



**8 декабрьдә татар җәмәгатьчелеге професссор, татар теле галимәсе, Казан университетының (хәзерге КФУ) татар филологиясе һәм тарихы факультетының гамәли тел белеме һәм тәрҗемәчелек кафедрасын җитәкләгән Флёра Садри кызы Сафиуллинаны соңгы юлга озатты.**

Галимәне озатырга шәкертләре, университет галимнәре, фән һәм җәмәгать эшлеклеләре, каләм әһелләре, татар зыялылары килгән иде. Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәиз дә галимә белән хушлашуда катнашты.

Флёра ханымның бар тормышы Казан университеты, шушы уку йортында татар телен өйрәнү һәм аны өйрәтү белән бәйле дияргә була. Чыгышы белән Татарстанның хәзерге Тукай районында урнашкан Теләнче Тамак авылы кызы 1955 елда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керә. Университетны тәмамлагач, татар теле кафедрасында башта лаборант, аннары ассистент булып эшли башлый.

1965 елда аспирантураны тәмамлый, күренекле тел белгече Мирфатыйх Зәкиев җитәкчелегендә "Татар телендә сүз тәртибе" дигән темага кандидатлык, 2000 елда татар әдәби теленең синтаксис төзелешенә багышланган докторлык диссертациясен яклый.

1992 елда Флёра ханым университетта яңа ачылган "Чит телле даирәдә татар теле" кафедрасын җитәкли башлый һәм соңгы вакытка кадәр шул вазифаны башкара.

Кырык елдан артык фәнни эшчәнлеге дәверендә Флёра Сафиуллина гаять бай мирас калдырды - татар теле гыйлеме өлкәсендә йөздән артык монография, дәреслекләр, сүзлекләр, укыту әсбаплары, мәкаләләр. Иң мөһиме - Флёра ханым үзе тәрбияләп үстергән, аның эшен дәвам итәрдәй шәкертләре - мәктәбе кала. Бу шәкертләрнең күбесе Флёра апаны "икенче әниебез" дип йөртә иде. Урыныгыз җәннәттә булсын!

Күренекле галимә Казандагы Иске татар зиратында җирләнде.

# ЙӨЗЕМ СУЫНА ЧУМГАН ПАДИШАҺ

Падишаһлардан бер падишаһның вәзире ул падишаһка әйтте:

- Хезмәткәрләреңә әмер ит: эченә кеше кереп чумарлык йөзем ширәсе, ягъни йөзем суы хәзерләт. Ширәне мичкәгә тутырсыннар, ә үзең шунда чум, - диде.

Падишаһ шундук боерды, бер мичкәгә кеше чумарлык итеп ул ширәне тутырдылар. Падишаһ хадимнәре белән мичкә янына килде. Хадимнәрнең кайсы падишаһның асылташлар белән бизәлгән таҗын тотып торды, кайсы киемнәрен, кайсы башмагын алды.

Шаһ ширәгә чумды, аннан башын чыгарды: үзен бер далада күрде, һәр дүрт ягына каранды, һичбер җан иясен күрмәде. Мәгәр бер карт очрады, ул карттан сорады:



- Бу ни атлы сахра? Карт җавап бирде:

- Бу сахраны Дәште Кыпчак дип әйтәләр.

Шаһ үзенең шәһәрен сорашты. Карт "фәлән кадәр тукталышлар үтеп барырга" кирәклеген әйтте. Шаһ моның чиксез ерак икәнлеген аңлады, үз гомерендә кайтып җитәр мөмкинлеге юк икән. Һәр дүрт тарафны сорады, һәр тарафтагы шәһәрләр бик ерак икән.

Карт:

- Үзең ни җирдән, кайчаннан бирле киләсең? - диде.

Шаһ барысын да әйтеп бирде. Карт аны үзенә кунак итеп алып кайтты. Бу шаһ ул картка күп көннәр хезмәт итте. Шаһка картның кызын никах итеп бирделәр. Шаһның күңеленә бу картның кызы хуш килде, көннән-көн мәхәббәтләре артты, берничә балалары дөньяга килде. Ул балалары чиксез сөекле булды.

Көннәрдән бер көнне бу падишаһ су коенырга теләде. Киемнәрен салып, суга керде дә чумып китте. Судан башын чыгарып караса, үзен әүвәлге йөзем ширәсе эчендә күрде. Хадимнәр дә шунда хәзер булып торалар: килеп чыгуы белән кайсы тәнен сөртеп, кайсы киемнәрен иңенә салдылар. Солтанлык тәхетенә илтеп утырттылар.

Падишаһ гамьгә чумып, башын иеп уйланып утырды, сәгать саен аһ орды.

Вәзире әйтте:

- И падишаһ! Ни булды?

Шаһ башыннан кичкәннәрне сөйләп бирде. Аннан соң вәзире әйтте:

И падишаһ! Ул күргән хәлләрең хыялдыр, әмма бу һәркемгә бер гыйбрәттер, дөньяның фанилыгының мисалыдыр, - диде. Шулай итеп, нәсихәтен тәмам итте.

**"Гыйбрәтле хикәятләр" китабыннан алынды**

«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. №17 (114) чыгарылыш.
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** Е-517.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 8 декабрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан сакланыгыз!**